| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«МИЧУРИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«МИЧУРИН<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 27 октябре № 4

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлегенең Яңа Сережкино авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм файдалану буенча гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1.Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлегенең Яңа Сережкино авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 20 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлегенең Яңа Сережкино авылында территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм тыл хезмәтчәннәре, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, 1 нче төркем инвалидлардан тыш, 500 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

- Яңа Сережкино авылы юлларын кардан чистарту;
-Яңа Сережкино авылындагы Лесная урамы буенча зиратка кадәр авыл эчендәге юлны чокырларны ямау

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мичурин авылы, Совет ур., 26 йорт-административ бина, Совет ур., 28 йорт-мәдәният йорты бинасы; Яңа Сережкино авылы, Үзәк ур., 9 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чykканнан соң үз көченә керә.

«Мичурин авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Р.Ә.Иванова